КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2026 ел, 15 май г.Казань № 702

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар, конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2015 ел, 21 гыйнвар, 27 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 20 гыйнвар, 25 нче; 2017 ел, 21 март, 167 нче; 2017 ел, 29 декабрь, 1113 нче, 2019 ел, 20 сентябрь, 861 нче, 2020 ел, 14 август, 684 нче, 2021 ел, 31 май, 399 нчы, 2022 ел, 30 декабрь, 1512 нче, 2023 ел, 22 март, 316 нчы, 2024 ел, 17 декабрь, 1151 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Юридик затларга сәламәтлек саклау өлкәсендә чаралар (семинарлар, форумнар, конгресслар,

конференцияләр, киңәшмәләр, симпозиумнар, съездлар, тренинглар, саммитлар) үткәрүгә бәйле булган чыгымнарны каплау өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 пунктта «шулай ук физик затларга – товарлар, эшләр, хезмәтләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктның икенче абзацына «, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләре вәкаләтле органга җиткерелгән көннән соң килә торган көннән алып 10 эш көне эчендә» сүзләрен өстәргә;

15 пунктның дүртенче абзацында «исәп-хисап яки корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

31 пунктта «исәп-хисап яисә корреспондент» сүзләрен төшереп калдырырга;

36 пунктның беренче абзацында «Бирелгән субсидия кире кайтарылырга тиеш» сүзләрен «Бирелгән субсидия акчалары кире кайтарылырга тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

37 пунктның беренче абзацында «субсидияне кире кайтару» сүзләрен «субсидия акчасын кире кайтару» сүзләренә алмаштырырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин